КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 25 ноябрь г.Казань № 1060

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе турында» 2006 ел, 30 октябрь, 529 нчы карары белән расланган Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе турында» 2006 ел, 30 октябрь, 529 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 27 сентябрь, 513 нче; 2007 ел, 29 декабрь, 765 нче; 2008 ел, 14 май, 311 нче; 2008 ел, 5 декабрь, 866 нчы; 2009 ел, 24 апрель, 263 нче; 2010 ел, 19 гыйнвар, 18 нче; 2010 ел, 9 июнь, 458 нче; 2010 ел, 13 август, 656 нчы; 2010 ел, 6 декабрь, 1001 нче; 2011 ел, 10 май, 372 нче; 2012 ел, 4 апрель, 270 нче; 2012 ел, 1 июнь, 462 нче; 2012 ел, 20 октябрь, 877 нче; 2013 ел, 17 апрель, 259 нчы; 2013 ел, 7 октябрь, 731 нче; 2014 ел, 23 гыйнвар, 32 нче; 2015 ел, 3 март, 129 нчы; 2015 ел, 31 июль, 553 нче; 2016 ел, 10 декабрь, 915 нче, 2017 ел, 3 июнь, 334 нче һәм 2018 ел, 16 май, 370 нче; 2019 ел, 13 сентябрь, 823 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составыннан Р.Р.Баһаветдиновны, Р.Т.Борһановны, А.Б.Гревцовны, А.Р.Зариповны, Л.Р.Сафинны, Б.Л.Смирновны чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

«Тормыш эшчәнлеге иминлегенең фәнни үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры вазыйфаларын башкаручы Евгения Евгеньевна Воронинаны;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы Марат Шамил улы Долговны;

Транспорт өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Урта Идел төбәкара дәүләт автомобиль юлы күзәтчелеге идарәсендәге идарә башлыгы вазыйфаларын башкаручы – баш дәүләт инспекторы Радик Вахит улы Рамазановны (килешү буенча);

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәетгәрәй улы Сәлимгәрәевны;

Бөтенроссия халык фронтының Татарстан Республикасындагы Төбәк башкарма комитеты җитәкчесе Ринат Рафаэль улы Фазыловны (килешү буенча);

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры Илсур Гәрәй улы Һәдиуллинны;

Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Фәрит Мөдәррис улы Хәнифовны;

Роза Шәйхәйдәр кызы Әхмәдиеваның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«югары белем бирүче «Казан дәүләт мәдәният институты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча)»;

Илназ Нуретдин улы Зиатдиновның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсендәге юл инспекциясе һәм хәрәкәтне оештыру бүлегенең махсус йөкләмәләр буенча инспекторы, комиссия секретаре (килешү буенча)»;

Рәфис Җәүдәт улы Хәбибуллинның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе башлыгы (килешү буенча)»;

Айрат Ринат улы Хәйруллинның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин